Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең
Яңа Еланъ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

19 ноябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 19 ноябре 14 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сораулар буенча "Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авылы җирлеге Яңа Еланъ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: бию мәйданчыгын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу?» сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 31 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 18 кеше, бу 58,1% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 18-е «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яңа Еланъ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яңа Еланъ авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: бию мәйданчыгын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Яңа Еланъ авылы, Үзәк урам, 35 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Е.Г.Николаева